**СОВЕТ ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район
д. Чернышевка, ул. Клубная, 1

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Чернышевка авылы, Клуб ур, 1

Тел./факс: +7(84365) 73-5-05, e-mail:Chern.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**08 сентября 2020 ел** **№ 229**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлеше, 2004 елның 28 июнендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Чернышевка авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 июнендәге 188 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсен раслау турындагы» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсенең 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 16 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга торак урыны бирү.».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы О.А.Маланин